| | |
|---|---|
| **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**СПАС МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ**<br>**БОЛГАР ШӘҺӘРЕ**<br>**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** | **БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ**<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**<br>**СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**<br>**РАЙОНА**<br>**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** |

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

№ 53 « 29 » июнь 2022 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитетының «Гемодиализ үткәрүгә мохтаҗ затларга транспортта йөрү чыгымнарын билгеләү һәм түләү тәртибен раслау турында» 2020 елның 1 сентябрендәге 55 номерлы карары (2021 елның 29 гыйнварындагы 9 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалanучы затларга амбулатор гемодиализ узу урынына бару һәм яшәү урынына кире кайту чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Халык сәламәтлеген саклау һәм ныгыту өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Башкарма комитетының «Спас муниципаль районы «2022 - 2024 елларга халыкның сәламәтлеген яхшырту һәм үлеп-китү санын киметү» муниципаль программасын раслау турында» 2012 елның 22 июнендәге 370 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Болгар шәһәр башкарма комитетының 2020 елның 1 сентябрендәге 55 номерлы карары белән расланган амбулатор гемодиализ ысулы белән дәвалanучы хроник бөер җитешсезлеге белән интегүче затларга амбулатория гемодиализы узу урынына транспортта бару чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) тәртипнең 4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Айлык компенсация күләме, факттагы чыгымнардан чыгып, гемодиализ үткәрү урынына бару бәясен киметү юлы белән, ләкин йөртү документларында күрсәтелгән бер сәфәр өчен 1500,00 сумнан да артмаган йә

медицина белешмәсендә күрсәтелгән айга гемодиализ үткәрү буенча йөрү бәясе турында белешмәдә билгеләнә».

2. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында http:// www. spasskiy.tatarstan.ru һәм хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (//http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Болгар шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Костина